| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**26.06.2017** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1826** |

Мөрәҗәгать итүчеләрнең конкурс гаризаларын карау һәм субсидия алу хокукына ия эшмәкәрлек субъектларын билгеләү буенча комиссия составы турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы карары, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының ««Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 24 маендагы 1445 карары , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү тәртибе турында» 2017 елның 17 маендагы 1331 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 июнендәге 1582 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең конкурс гаризаларын карау һәм субсидия алу хокукына ия эшмәкәрлек субъектларын билгеләү буенча комиссия составын расларга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru ) рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) мәгълүмат сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин